## Музыкага гашыйк шагыйрь

*(Музыкаль кичә)*

Җиһазлау: Китап күргәзмәсе, Г.Кутуй портреты белән янәшә С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи портретлары куела.

**Алып баручы:** Г.Кутуй күпкырлы иҗат кешесе. Ул иң элек язучы, шагыйрь, драматург, публицист, тәнкыйтьче. Аның тагын бер ягы бар ул концертлар, әдәби кичәләр оештыручы, искиткеч сәнгатьле итеп шигырьләр укучы. Бөек Ватан сугышы башланганчы ул Казанда иң популяр конферансье була. Спай гәүдәле, кара бөдрә чәчле, көләч йөзле Г.Кутуй һәр артистны күңелле бүләк тапшыргандай, тамашачыларга шатланып, хөрмәтләп тәкъдим итә торган була. Концертлар да гел күтәренке рухта бара.

Г.Кутуй музыка тәнкыйтьчесе дә. Музыка тормышындагы һәр вакыйга аның игътибарын ялый. Аның музыка сәнгате турындагы мәкаләләре генә дә утыздан артык. Ул татар опера сәнгатенә кыйммәтле әсәрләр белән килгән Н.Җиһановның «Качкын», «Ирек» операларына рецензияләр яза.

1939 елда Г.Кутуй татар-башкорт көйләрен җыя, аларны җентекләп өйрәнә, үзен симфоник әсәрләрдә сынап караган А.С.Ключарев турында язучылар клубында чыгыш ясый. Композитор әсәрләреннән әдипләр өчен концерт оештыра. Радиоконцертларга башлап рецензия язучы да ул. *Н.Җиһанов Г.Кутуйның «Партизанка» шигыренә язган көй башкарыла.*

**2 нче алып баручы:** Гөлсем Сөләйманованың җырлавы турында Г.Кутуй «Кызыл Татарстан» газетасының 1940 елгы 10 октябрь санында болай дип яза: «Татарстанның атказанган артисткасы Гөлсем Сөләйманова үзенең җаваплы чыгышында татар халкының «Әллүки», «Минзәлә», «Өнсә» көйләрен һәм «Ташкыннар» пьесасыннан Гайнавал җырын башкарды. Һәрбер җыр Сөләймановага хас табигый күркәм тавыш, колакка ягымлы моң һәм җырның һәр авазы яңгырап торган ачыклык белән үтәлде. Сөләймановада халык көйләрен, андагы гүзәллекне бозмыйча, җылы һәм матур башкару сәләте бар.

*Гөлсем Сөләйманова язмалары тыңлап үтелә.*

**3 нче алып баручы:** Казанга килүенең беренче көннәрендә үк Г.Кутуй С.Сәйдәшев белән таныша, дуслаша һәм аның иҗаты турында фронтка киткәнче рус һәм татар газета-журналларында күп тапкырлар фикерләре белән урталаша. С.Сәйдәшевның дирижерлыгын да, пианист-аккомпаниатор булуын да күзәтеп бара, матбугатта язып чыга, композитор иҗатына югары бәя бирә, аның сәнгатьтәге урынын югары бәяли. «Үзенең гүзәл әсәрләрендә Сәйдәшев яңа кешенең рухын, аның эчке кичерешләрен бик оста бирә белә. Аның әсәрләре тирән патриотизм белән сугарылган... Татар совет музыкасына нигез салучы, беренче татар операларына этәргеч булып торырлык бик күп музыкаль драмалар иҗат иткән Сәйдәшев таланты алдында безнең сәнгатебез зур бурычлы», — дип яза ул Салих Сәйдәшев һәм татар музыкасы исемле мәкаләсендә. Г.Кутуйның үз иҗат җимешләре дә музыка әсәрләре туугa җирлек булып тордылар.

1928 елдан башлап С.Сәйдәшев, Г.Кутуй драмаларына музыка иҗат итә. Шул ук елның 3 гыйнварында Татар драма театры сәхнәсендә кырым татарлары тормышыннан «Нәнкә җан» исемле музыкаль спектакль куела. Ә 25 көннән соң «Калфаклылар» дигән музыкаль комедияне тәкъдим итәләр. 1929 елда Г.Кутуйның «Күк күгәрчен» драмасы куела. С.Сәйдәшев бу драмага да музыка яза.

*С.Сәйдәшев көйләре яңгырый.*

**4 нче алып баручы:** Г.Кутуй яшь музыкантларга үтә дә игътибарлы була. Музыкада үзен өйрәнчек итеп хис иткән Җәүдәт Фәйзигә, Заһит Хәбибуллинга беренче ярдәм кулын суза, аларны иҗатка өнди. Җыр җанрында беренче тәҗрибә итеп Җ.Фәйзи Г.Кутуйның «Карт пычкычы» дигән шигыренә көй яза. З.Хәбибуллин Г.Кутуйның «Шатлык»

пьесасына 1936 елда музыка язуын сагынып искә ала. Бөек Ватан сугышы башлангач, З.Хәбибуллин Г.Кутуй белән бергә «Команда, алга», дигән җыр иҗат итә. Ул җиңү көненә кадәр көрәшкә рухландыручы җыр-марш булды, җырчыларның репертуарларыннан төшмәде.

*З.Хәбибуллин язган көйләр яңгырый.*

**5нче алып баручы:** 1946 елда Кутуй истәлегенә М.Мозаффаров язган «Туган ил» җыры — Ватаныбыз турындагы лирик җырларның иң ихлас күңелдән иҗат ителгәннәренең берсе. Ул җыр меңнәрнең күңелләрендә саклана.

И, туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

1941 елның көзендә элекке Кайбыч районының Чәчкап авылында окоп казыган вакытта Кутуйның Җ.Фәйзи белән бергә иҗат иткән «Иделкәем»ен инде бүген халык җыры итеп кабул итәләр. Сез барыгыз да беләсез инде, «Тапшырылмаган хатлар» нигезендә ике опера туды. Җ.Фәйзи «Тапшырылмаган хатлар» операсын Татарстанның 40 еллыгына багышлап язды. Ул 1960 елның 24 июнендә М.Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театрында беренче тапкыр уйналды.

Г.Кутуй кыска гомерле булды. Әмма шул кыска гына гомерендә дә ул татар музыкасын үстерүгә, аның жанрларын баетуга зур өлеш кертте.

*Җ.Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» операсыннан музыкаль өзек уйнатыла.*

**6 нчы алып баручы:** Гадел Кутуй — заман рухын, ил сулышын нечкә тоя белүче шагыйрь һәм публицист. Ул һәрвакыт әдәбият, театр һәм музыка тормышының үзәгендә кайный. Татар академия театры сәхнәсендә берәр яңа әсәр куелдымы, Гадел Кутуй бер-ике көннән алар турында газеталарда рецензияләр бастырып чыгара, артистлар башкарган концертлар хакында үз фикерен җиткерә. Г.Кутуй музыка сәнгатен бик яхшы белә. Ул бигрәк тә җыр жанры белән тирәнтен кызыксына. Шуңа күрәдерме, аның күп кенә шигырьләренә көй язылган.

Г.Кутуй актив эшли, күп иҗат итә. Ул киң эрудицияле булуы белән бергә, бик оста оештыручы буларак та танылa.

Г.Кутуйны Н.Җиһанов белән иҗат дуслыгы гына түгел, чын дуслык җепләре дә бәйли. Сугышка китәр алдыннан, Г.Кутуй Н.Җиһанов белән таң атканчы урамда йөриләр. Шунда Г.Кутуй Н.Җиһановка: «Мин үземне фронтта да күрсәтәчәкмен, батыр сугышып, фашистларның күбесенең башына җитәчәкмен», — ди. Әйе, шагыйрь һаман көрәшчеләр сафында. Аның иҗаты әдәбият гөмбәзендә якты йолдыз булып яна.

*Кичә Н.Җиһановның музыкаль әсәрләрен башкарып тәмамлана.*

**Кулланылган әдәбият:**


Татар телендә:

1. Хәйруллина З. Музыкага гашыйк шагыйрь // Социалистик Татарстан. - 1983. -27 нояб.

2. Тәхау К. «Ул язучылар илчесе иде»: Н.Җиһановның Г.Кутуй турында истәлекләре // Социалистик Татарстан. - 1985. - 16 июль.

3. Мирзиянова Ф.Н. Татар халык музыкасы. - Лениногорск, 1998. — 252 бит.

Рус телендә:

1. Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. - Казань, 1985. — 208 с.

2. Миннуллина Л.А. Литературное творчество Назиба Жиганова. - М.: Композитор,1996. — 131 с.

3. Сайдашева З.Н. В мире татарской музыки: Казань, 1995. — 125 с.

**Г.Кутуйның шигырьләренә һәм пьесаларына композиторларыбыз иҗат иткән әсәрләр исемлеге:**

1. Салих Сәйдәшев. «Нәнкә җан» спектакленә, «Калфаклылар» музыкаль комедиясенә, «Күк күгәрчен» драмасына, «Балдызкай» пьесасына.
2. Нәҗип Җиһанов. «Партизанка» шигыренә.
3. Җәүдәт Фәйзи. «Карт пычкычы», «Иделкәем» шигырьләренә, «Тапшырылмаган хатлар» операсына.
4. Заһит Хәбибуллин. «Шатлык» пьесасына 1936 елда, «Команда, алга» шигыренә.
5. Мансур Мозаффаров. «Туган ил» җырына.

Чыганак: **Заман һәм аның ялкынлы җырчысы: Галел Кутуйның(1903-1945) тууына 100 ел тулуга багышланган методик һ.библиогр.ярдәмлек / ТР Милли к-ханәсе;Төз.Р.Ә.Хөсәенова. – Казан: Милли китап., 2003. – 47 б.**